Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Пестречинского
муниципального района
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль
районы
башкарма комитеты
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» октябрь, 2024 ел № 806

2024 елның дүртенче кварталына салым салынырга тиешле граждannар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыгының 2024 елның 28 августындагы 334 номерлы хаты, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 3 400 732,5 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 4 328 205,00 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 5 564 835,00 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 7 419 780,00 сум

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 9 274 680,00 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 11 129 616,00 сум

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 12 984 615,00 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 37 133,00 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 23 630,00 сум

1.2.3. Өч һәм аннан күбрәк кеше өчен - 24 305,00 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондын исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемле дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И. Р. Дәүләтханов